**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КҮЗКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«01» ноябрь 2023 ел №11/2

**«Җир салымы турында» «Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 5/3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Җир салымы турында» «Күзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 5/3 номерлы карарына түбәндге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктчаны өстәргә:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары, 2023 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла. Салым ташламасы салым түләүчеләргә салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында, районның рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң бер ай узгач үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Э.Р. Гәрәев